ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт,Печищи авылы,
422592

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

11.12.2025 | 73

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 ст. , «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Октябрьский җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш.Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11.12.2025 ел №73 карарына
Кушымта №1

Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 01.01.2026 елдан 31.03.2026 елга кадәр Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар - Октябрьский поселогы, Матюшино авылы, Ключищи авылы гражданнар җыенында катнашуга һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, гамәлгә ашырыла.

3. Түләүләр күләме түбәндәге категория гражданнар өчен гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) күпбалалы гаиләләр;

4. Гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманы түләүдән түбәндәге категорияләр азат ителә:

а) СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (ата-аналар, ир белән хатын, балалар).

5. Бер мәртәбә бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Үзара салымнан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почта күчерүен (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашырып, яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының https://uslugi.tatarstan.ru/ ссылкасы аша башкарыла.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11.12.2025 ел №73 карарына
Кушымта №2

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР)№ ________

Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И.А.и.
______________________________________________________________

Адрес: _____________________________________________

_________________________________________________ нигезендә

Сезгә ____________________ вакытына кадәр ______________________

чараларны гамәлгә ашыруга _____________________________________ суммасында, түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:

БИК алучының банкы _________ / Сч. № ____________________________

Алучы Сч. № ____________ / ИНН ________ / КПП ____________________ / ОКАТО _________

Түләү билгеләү ____________________________________

Җитәкче ______________   _________________________________

М. у. (имза) (имза расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - -кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Үзара салым буенча бер мәртәбә бирелә торган түләүне бюджетка (муниципаль берәмлекнең исеме) түләү турында хәбәрнамә (хәбәр) ________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф. И.А.и. _____________________________________________

Адрес:____________________________________________________________

Алдым «__» _________________ 20___ ел. ______________________________

(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Өзек өлеше тутырыла һәм хәбәрнамә түләүчегә шәхсән үзе тапшырылган очракта __________ җирлек Башкарма комитетында кала.